ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Шмаков шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2019 елның 24 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.А. Шмаков шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.А. Шмаков «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 8.2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъвалана торган нигезләмә буенча билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның

1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә (алга таба шулай ук — Исемлек) кергән авыру буенча икенче төркем инвалиды һәм ул торак шартларын чираттан тыш тәртиптә социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак 2018 елда исәпкә куелган.

Гражданин А.А. Шмаков фикеренчә, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты буенча ул торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аны исәпкә куйган көннән алып биш эш көне эчендә аның турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына субсидия алучыларның җыелма исемлеген төзү өчен җибәрергә тиеш булган. Үз чиратында аның торак шартларын социаль наем

шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелуы турында мәгълүмат Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Совет районы администрациясеннән килергә тиеш булган. Ләкин гражданин А.А. Шмаков билгеләгәнчә, хәзерге вакытка кадәр аның документлары билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органга җибәрелмәгән, шуңа бәйле рәвештә ул судка мөрәҗәгать иткән, аның карары белән дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән, аларның җавапларыннан күренгәнчә, аны торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алучыларның җыелма исемлегенә кертү өчен ул өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш.

Гражданин А.А. Шмаков күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 8.2 статьясы 2014 елда кертелгән һәм беренче редакциясендә торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) торак урыннарга мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан инвалидларның аерым категорияләренә бирүне күздә тоткан. Әмма 2015 елның 5 декабрендә Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы дәгъвалана торган 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ» сүзләренә үзгәртелгән.

Мөрәҗәгать итүче ассызыклаганча, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктын үтәү максатларында кертелгән, шулай да әлеге Кодексның 51 статьясында инвалидларның югарыда күрсәтелгән категориясенә керә торган гражданнар, аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ дип тану

максатларында, өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган булырга тиеш дигән өстәмә таләп юк. Шул ук вакытта ул социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нигезләре һәм тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексының 7 бүлеге, ә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нигезләре һәм тәртибе әлеге Кодексның 8.1 һәм 8.2 бүлекләре тарафыннан җайга салына дип билгеләп үтә. Ягъни ул федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары арасында каршылыклар күрә һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 4 статьясындагы 2 өлеше нигезендә федераль законнарның Россия Федерациясенең бөтен территориясендә өстен булуын ассызыклый. Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 8 өлеше нигезендә федераль законнардагы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларындагы, Россия Федерациясе субъектлары законнарындагы һәм башка норматив хокукый актларындагы, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларындагы торак законнары нормалары әлеге Кодекс нигезләмәләренә туры килмәгән очракта Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләре кулланыла.

Димәк, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, инвалидларның югарыда күрсәтелгән категориясенә, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ дип танылганнан соң һәм торак мәйданы белән тәэмин ителүгә чираттан тыш хокуклары булган затлар исемлегенә кертелгәннән соң да, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип өстәмә рәвештә танылу күрсәтмәсен бирә торган Татарстан Республикасы законнары таләбе законсыз һәм кулланылырга тиеш түгел.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.А. Шмаков Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка

адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктын Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш булуы өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 1 (беренче өлеш), 2, 4 (беренче өлеш), 13, 27 (беренче өлеш), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданин А.А. Шмаков тапшырган материалларны өйрәнеп, аның шикаятен карауга алу өчен нигезләр тапмый.

Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 1 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын берничә тапкыр тәшкил иткән иде инде. Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең билгеләмәләрендә билгеләп үткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән каралган хокукый җайга салу гражданнарның торакка конституциячел хокукын аларга максатчан субсидия бирү юлы белән тәэмин итүнең өстәмә гарантиясе булып тора, гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан аларның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру ысулын билгеләүгә, шулай ук алар исәбенә башкалар белән беррәттән инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр кертелгән гражданнарның әлеге категорияләрен билгеләүгә юнәлгән. Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Конституция суды күрсәткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән хокукый җайга салу гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә

алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы, 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы, 2018 елның 10 сентябрендәге 19-О номерлы һәм 2018 елның 28 сентябрендәге 29-О номерлы билгеләмәләр).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә дә туры килеп тора, ул билгеләп үткәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Дәгъва белдерелә торган норма нигезендә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү шарты булып Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларны билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип тану тора. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән расланган. Әлеге Тәртипнең 2.1 пункты буенча күрсәтелгән гражданнарны исәпкә алу алар тапшырган гаризалар һәм кирәкле документлар нигезендә башкарыла. Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә шундый гражданнарга торак сатып алу өчен субсидияләр бирү субсидия алучылар билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының исемлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан төзелгән субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлеге буенча чират тәртибендә башкарыла.

Югарыда күрсәтелгәннәрдән аңлашылганча, Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга дәгъвалана торган норма белән каралган хокукын гамәлгә ашыру, гражданин А.А. Шмаков дәлилләренә карамастан, мөрәҗәгать итү характерына ия һәм аны алырга теләгән гражданнардан билгеле бер гамәлләр кылуны таләп итә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәсе Татарстан Республикасына бирелгән вәкаләтләр кысаларында кабул ителгән, анда үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр юк, гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Гражданин А.А. Шмаковның конкрет эше буенча суд карарларының һәм хокук куллану органнары вазыйфаи затлары карарларының законлы һәм нигезле булу-булмавы турындагы мәсьәләне, шулай ук мөрәҗәгать итүче куйган башка мәсьәләләрне хәл итү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты белән Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алу өчен өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш булуы өлешендә үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Шмаков шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган башка мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин А.А. Шмаковка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 2-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**